Гали баба



һәм кырык карак

Татгосиздат 1950

Гали баба һәм кырык карак



III БАСМА

ТАТГОСИЗДАТ
ЯШЬЛӘР - БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1950

*
* *

Тәрҗемәчесе
Г. ГОБӘЙ

*

Җаваплы редакторы
А. ӘХМӘТ

*

Художник
Л. ФӘТТАХОВ
Рәсемнәре

* *
*



Борын-борын заманда Иран шәһәрләреннән бер шәһәрдә берсе Касыйм, берсе Гали-Баба исемле ике туган бар иде. Аталары үлгәч, алар аннан калган акчаны үзара бүлештеләр. Касыйм базарда кыйммәтле кызыл маллар һәм ефәк җиләннәр белән сату итә башлады. Ул үзенең товарын мактый белә иде, алучыларны кызыксындыра белә иде, шуңар күрә аның кибетендә һәрвакыт халык кайнап торды һәм Касыйм баеганнан-байый барды. Ул, бер заман, күп итеп акча җыйгач, өлкән судьяның Фатыйма исемле кызына өйләнде.

Ә Гали-Баба сату итә дә, акча җыя да белмәде. Ул Зәйнәп исемле фәкыйрь бер кызга өйләнде. Алар ни булган байлыкларының бөтенесен диярлек, бик тиз туздырып бетерделәр һәм бер тапкыр Зәйнәп иренә болай диде:

— Кара әле, Гали-Баба, болай булса, тиздән безнең ашарыбызга да калмас. Сиңа нәрсә булса да уйларга кирәк булыр, юкса без ачтан үләрбез.

Гали-Баба:

— Яхшы, мин бу турыда уйлап карармын,—дип җавап бирде. Ул, бакчага чыкты да, бер агач ышыгына утырып уйлый башлады. Уйлады, уйлады Гали-Баба һәм, ниһаять, уйлап тапты. Ул, калган акчаларын алып чыкты да, базардан ике ишәк, балта һәм озын гына бау сатып алды.

Икенче көнне ул иртә белән шәһәрдән чыгып, куе урман белән капланган биек бер тауга китте һәм көне буе шунда утын кисте. Кич белән утыннарын, бәйләм-бәйләм итеп бәйләп, ишәкләренең аркаларына салды да шәһәргә кайтып китте. Ул утыннарын базарда сатты да ипи, ит һәм яшелчәләр алды.

Шуннан бирле Гали-Баба һәр көн иртә белән тауга барып кичкә кадәр утын кисте, ә аннан соң базарга алып кайтып сатты да, үзенә һәм Зәйнәпкә ипи белән ит сатып алып кайтты. Бер тапкыр шулай Гали-Баба озын бер агачны кисәргә дип кенә торганда, юл өстендә тузан күрде. Тузан күккә кадәр күтәрелгән иде. Ә тузан басылгач, Гали-Баба атка атланган тимер киемле кешеләрнең туп-туры үзенә таба килгәннәрен күрде. Тимер киемле кешеләрнең иярләрендә сөңгеләр, ә билбауларында озын-озын үткен кылычлар ялтырый иде. Отрядның алдында, зур ак ат өстендә бер күзле, кара сакаллы кеше чабып килә иде.

Гали-Баба бик нык курыкты. Ул тиз генә агач башына менде дә ботаклар арасына кереп яшеренде. Атлы кешеләр әле генә Гали-Баба басып торган урынга килеп җиткәч, атларыннан сикереп төштеләр һәм һәркайсы ияр өстеннән берәр авыр капчык алып иңбашларына салдылар. Аннан бер сафка тезелеп Беркүзленең боерыгын көтә башладылар. Бу Беркүзле аларның атаманнары иде.

„Болар кемнәр икән, капчыкларында нәрсә икән? Мөгаен юлбасарлардыр әле“,—диде үзенә-үзе Гали-Баба.

Гали-Баба тимер киемле кешеләрне санап чыкты. Атаманнан башка кырык кеше. Менә атаман кырык кешенең алдына килеп басты да аларны биек кыяга таба алып китте. Кыяның корыч ишеге бар иде, тирә-ягына чирәм һәм чәнечкеле куаклар үскәнлектән бу ишек бөтенләй диярлек күренми дә иде.

Атаман ишек янына килеп туктады да бик каты итеп кычкырып җибәрде:

— Симсим, ач ишекне!

Һәм, кинәт, кыя ишеге ачылып китте. Атаман эчкә керде, аның артыннан бүтәннәр дә керделәр һәм ишек яңадан шапылдап ябылды.

„Менә бу могҗиза дисәң дә могҗиза! Симсим бит ул бер кечкенә генә үсемлек. Мин аңардан май чыкканны беләм, ләкин мин аның ишек ача алганын белми идем әле“, — диде Гали-Баба.

Гали-Бабаның сихерле ишекне якыннанрак күрәсе килде, ләкин ул юлбасарлардан шул хәтле курыкты, агач башыннан төшәргә дә батырчылык итмәде.

Бик күп вакыт үткәч, ишек яңадан ачылып китте һәм аннан кырык карак буш капчыклар тотып чыктылар. Беркүзле атаман бу юлы да алда иде. Юлбасарлар, буш капчыкларны иярләренә бәйләделәр дә, атларына менеп чаптырып китеп тә бардылар.

Юлбасарлар китүгә, агач башында бөрешеп утыра-утыра арып беткән Гали-Баба тиз генә җиргә төште дә кыя янына йөгереп килде.

„Әгәр мин дә шулай: Симсим, ач ишекне дисәм нәрсә булыр икән? — дип уйлады ул. — Ишек ачылырмы икән, юкмы икән? Сынап карыйм әле!“

Ул, тирән итеп бер сулады да, батыраеп бөтен тавышына кычкырып җибәрде.

— Симсим, ач ишекне!

Һәм шунда ук ишек ачылып китте. Зур тау куышына юл ачылды.

Гали-Баба тау куышына керде. Ул бусагадан атлауга, ишек яңадан бикләнде. Гали-Баба бераз куркып китте. „Ә ишек яңадан ачылмаса һәм мин чыга алмыйча шушында бикләнеп калсам?“—диде Гали-Баба. Шулай да ул, як-ягына карый-карый, исе китеп алга атлады.

Бу зур бүлмәдә ул әллә нәрсәләр күрде. Стена буйларында алтын савыт-сабалар белән тулы өстәлләр күрде, тәмле аш исләре сизде, һәм үзенең иртәдән бирле ашамаган булуын хәтерләде. Ул бер өстәл янына килде дә табаклар өстендәге капкачларны ачып карады, һәм Гали-Бабаның авызыннан сулар килде, табакларда җаның ни тели, шул бар иде, кыздырган тавыклар, плау, вареньелы коймак, хәлвә, алмалар һәм башка төрле тәмле-тәмле әйберләр белән тулган иде өстәл.

Гали-Баба бер тавыкны алды да күз ачып-йомганчы чәйнәп йотты. Аннан плауга тотынды. Аның белән эшне бетергәч, хәлвәгә сузылды, ләкин хәлвәнең бер кисәген дә ашый алмады, — тамагы шул хәтле туйган иде. Бераз ял итте дә, як-ягына карана торгач, икенче бер бүлмәгә керә торган ишек күрде. Гали-Баба бу бүлмәгә кергәч, күзләре чагылып китте. Алтын һәм кыйммәтле ташлар анда шул хәтле күп иде — бөтен бүлмә җем-җем итеп тора иде. Алтын динарлар һәм көмеш дирханнар[1] диңгез ярындагы ташлар шикелле идәндә өелеп ята. Һәрбер почмакта кыйммәтле савыт-сабалар—кәсәләр, поднослар, асыл ташлар белән бизәлгән тәлинкәләр өелеп ята. Кытай, Һиндстан, Мисыр ефәкләре, кызыл маллар бүлмә уртасында аунап яталар. Стеналарда бер бөтен гаскәргә житәрлек үткен-үткен кылычлар һәм озын-озын сөңгеләр эленеп тора.

Боларны күргәч, Гали-Бабаның күзләре әле анда, әле монда йөгерде. Ул нәрсәгә дә барып тотынырга белмәде, әле кызыл ефәк җиләнне киеп карады, әле алтын подносны алып көзгегә караган шикелле карап торды, әле алтын акчаларны алып бер учыннан икенчесенә сибеп карады.

---

[1] Дирхан, динар — акча.



Ниһаять, ул әз генә тынычланды да, үз-үзенә болай диде:

— Бу акчаларны һәм кыйммәтле нәрсәләрне бирегә әлеге юлбасарлар урлап ташыганнардыр. Бу байлык аларның үзләренеке түгел, әгәр дә мин бу алтыннарның беразын алсам, начарлык эшләү булмас. Бирелә алтын санап бетергесез ич!

Гали-Баба җиләненең итәкләрен кыстырды да җиргә тезләнеп, алтын тутырды. Тау куышыннан ике буш капчык табып алып аларга да алтын тутырып ишек төбенә китереп куйды һәм кычкырып җибәрде:

— Симсим, ач ишекне!

Шулай диюгә ишек ачылып китте.

Гали-Баба тау куышыннан чыкты һәм ишек тагы ябылды. Чәнечкеле куаклар, агач ботаклары астында күздән югалган Гали-Бабаның ишәкләре аланда печән ашап йөриләр иде. Гали-Баба аларга алтынлы капчыкларны салды, утын белән томалады да өенә кайтып китте.

Ул кайтканда төн уртасы җитеп килә иде инде. Борчылып беткән Зәйнәп аны капка төбендә каршы алды.

— Шул гомердән бирле урманда нишләп йөрдең?—дип сорады Гали-Бабадан Зәйнәп.—Мин инде анда сине бүреләр ашап бетергәндер дип курыккан идем. Нигә син утыннарыңны сатмыйча өйгә алып кайттың?

— Хәзер, Зәйнәп, барысын да белерсең, әйдә, шушы капчыкларны өйгә алып керик әле, ләкин шаулама, күршеләр ишетмәсеннәр,—диде Гали-Баба.

Гали-Баба бер капчыкны үзенең аркасына салды, Зәйнәп тә берсен күтәрде, алар Гали-Баба белән өйгә керделәр. Зәйнәп ишекне яхшылап япты, лампаны кабызды һәм капчыкны чишеп җибәрде. Алтыннарны күргәч, ул куркуыннан агарынып китте һәм:

— Ни эшләдең син, Гали-Баба? Кемне таладың?—дип кычкырып җибәрде.

— Хафаланма, Зәйнәп, — диде Гали-Баба. — Мин беркемне дә таламадым. Мин хәзер сиңа бүген башымнан үткәннәрне сөйләп бирәм.

Ул Зәйнәпкә юлбасарлар һәм тау куышы турында сөйләде, һәм сүзен шулай дип тәмамлады:

— Кара аны, Зәйнәп, алтыннарны яшереп куй һәм бу турыда һичкемгә сөйлисе булма. Халык безне кеше талаган дип уйлар һәм патшага барып әйтер. Ул чакта, патша безнең алтыннарыбызны үзенә алыр да, безне җир астына ябып куяр. Әйдә, Зәйнәп, бер чокыр казыйк та, алтыннарны шунда күмеп куйыйк.

Алар бакчага чыктылар да ай яктысында бер чокыр казыдылар. Алтыннарның барысын да шунда тутырдылар һәм өстенә балчык өйделәр.

Эш беткәч, Гали-Баба йокларга ятты, Зәйнәп тә ятты, ләкин ул йоклый алмады, әле бер якка, әле икенче якка әйләнде ул һәм уйларга тотынды.

„Гали-Баба күпме алтын алып кайтты икән? Таң гына атсын, барысын да берәмләп санап чыгам“.

Икенче көнне иртә белән, Гали-Баба көндәгечә тауга киткәч, Зәйнәп йөгереп чыкты да чокырны ачып, алтыннарны алды һәм саный башлады.

Ләкин алтыннар шул хәтле күп иде, Зәйнәп аларны санап бетерә алмады. Ул яхшылап саный да белми иде, бераз санады да ялгышты, бераз санады да тагы ялгышты. Ниһаять, бу эш аны туйдырды. Ул үз-үзенә болай диде:

— Санап торганчы үлчәү белән генә үлчим. Ләкин безнең үлчәү юк. Фатыймадан сорап торырга туры килер.

Ә Касыйм белән Фатыйма күршедә генә торалар иде. Зәйнәп тиз генә шунда кереп китте, Фатыйма аны өй алдында каршы алды. Зәйнәп Фатыймага болай диде:

— Бер яхшылык ит әле, Фатыйма, әз генә вакытка үлчәвегезне биреп тор әле. Бүген үк кертеп бирер идем.

— Яхшы, лəкин минем үлчəвем күршедə иде əле. Хəзер кереп алып чыгып бирəм, шушында, өй алдында гына торып тор, аякларың бик пычрак икəн, əле генə яңа чыпта җəйгəн идем,— диде Фатыйма.

Фатыйма ялганлады. Ярма үлчи торган үлчəве үз урынында, кухняда, учак турысында гына эленеп тора иде аның. Чыптасы да ун көннəн бирле инде алыштырылмаган иде. Фатыйма, Гали-Баба йортында бертөрле дə ярма юклыгын яхшы белə һəм аның Зəйнəпкə тик торганда үлчəү ни өчен кирəк булганын белəсе килə иде. Лəкин ул бу турыда Зəйнəптəн сорашырга телəмəде. „Фатыйма Зəйнəп тормышы белəн кызыксына икəн дип борынын күтəрмəсен тагын“ диде. Һəм ул сорашмыйча белə торган əмəл уйлап чыгарды. Үлчəвенең төбенə бал сылады да Зəйнəпкə алып чыгып бирде, һəм болай диде:

— Мə, ал. Лəкин кояш баеганнан да соңга калмыйча кертеп бирергə онытма. Минем үземə ясмык үлчəргə кирəк булачак.

— Рəхмəт инде сиңа, Фатыйма,—диде Зəйнəп һəм өенə йөгерде. Ул барлык алтыннарны казып алды да, як-ягына карана-карана, ашык-пошык үлчəргə тотынды.

Алтын ун үлчəү ярым булып чыкты. Зəйнəп үлчəүне Фатыймага кертеп бирде дə җиргə кадəр иелеп рəхмəтлəр əйтə-əйтə чыгып китте. Фатыйма шунда ук үлчəүне алып эчен карады һəм үлчəү төбенə ябышкан ниндидер ялтыравыклы бер кечкенə түгəрəк күрде. Фатыйма үлчəү эченə кулын тыгып түгəрəкне алды.

Бу—кечкенə генə өр-яңа алтын динар иде.

Фатыйма үз күзлəренə ышанмады. Ул, акчаны бармак араларында əйлəндергəлəп, хəтта тешлəп тə карады—ялган акча түгелме икəн? Лəкин бу саф алтыннан коелган чын акча иде.

— Менə ул нинди ярма үлчəгəн!—дип кычкырды Фатыйма. Алар шул хəтле байлар, Зəйнəп алтынны да үлчəү белəн генə үлчи. Мөгаен алар кемне булса да талаганнардыр, ə үзлəре фəкыйрь

булган булып кыйланалар. Касыйм кибеттән тизрәк кайтсын иде! Мин аңарга барысын да сөйләп бирер идем. Касыйм Гали-Баба янына керсен дә, яхшылап куркытсын! Шулай итсә, Гали-Баба, әлбәттә, Касыймга өлеш чыгарыр.

Фатыйма бөтен көн буена Касыймны көтеп капка төбеннән кермәде. Караңгы төшә башлагач, Касыйм кибеттән кайтты. Фатыйма, аның чалмасын салганын да көтмичә, кычкыра башлады.

— Тыңла әле, Касыйм. Миндә бик кызык бер яңалык бар. Синең туганың Гали-Баба юри генә фәкыйрь булган булып йөри икән. Ул синең белән миннән баерак икән!

— Син нәрсә уйлап чыгардың? Миннән бай кеше бөтен урамда, бөтен кварталда юк. Базар башлыгы итеп мине тик томалга гына сайлап куймадылар,—дип Касыйм Фатыйманы ачуланды.

Фатыйма бу сүзгә үпкәләп болай диде:

— Әле син миңа ышанмыйсыңмы? Алайса әйт әле син миңа, сату итеп кайткач, син акчаңны ничек саныйсың?

— Гадәттәгечә саныйм,—дип җавап бирде Касыйм,—динарларны үзенә бер өемгә, дирханнарны үзенә бер өемгә өям дә саныйм. Йөзгә тулдымы, ялгышмас өчен, бармакны бөгеп куям. Тукта әле, нигә син миңа шундый юләр сорау бирәсең?

— Бер дә юләр түгел!—дип кычкырды Фатыйма.—Син менә динарларны унарлап та, йөзәрләп саныйсың, ә синең туганыңның хатыны Зәйнәп үлчәү белән генә үлчи. Бүген үлчәү алып торган иде, эчендә менә нәрсә ябышып калган.

Һәм Фатыйма иренә үлчәү төбендә ябышып калган динарны күрсәтте.

Касыйм акчаны як-яктан әйләндереп карады да болай диде:

— Гали-Бабага бу акчаларның кайдан килгән икәнен белә алмасам, исемем Касыйм булмасын! Хәйлә беләнме, көч беләнме, мин аңардан ул акчаларны тартып алачакмын!



Һәм ул шунда ук атасы янына кереп китте. Гали-Баба әле генә таудан кайткан икән, йорты алдындагы таш скамьяда ял итеп утыра иде. Касыймны күргәч, ул бик шатланды һәм:

— Рәхим ит, Касыйм! Син бездә бик сирәк буласың. Синең бүген минем яныма килүеңә нәрсә сәбәп булды? Җитмәсә шундый соң... — диде.

— Хәерле кич, туганым,— диде Касыйм эре генә итеп,— сиңа килүемә үпкәләвем сәбәп булды.

— Үпкәләү? — диде Гали-Баба гаҗәпләнеп. — Мин фәкыйрь утынчы, сине, базар башлыгын, нәрсә белән үпкәләттем икән?

— Син хәзер миннән баерак инде, — диде Касыйм. — Син алтынны да үлчәү белән генә үлчисең икән. Синең хатының Зәйнәп бездән үлчәү алып торган иде. Төбеннән минем хатыным менә нәрсә тапкан. Ялганлама миңа, мин барысын да беләм. Нигә син баеганлыгыңны миннән яшердең? Мөгаен син кемне булса да талагансыңдыр.

Гали-Баба, Касыйм серне белгән дип уйлады, һәм барысын да сөйләп бирергә карар кылды.

— Я, туганым минем,—диде ул.—Минем сине алдарга һич тә җыенганым юк...

Һәм ул Касыймга тау куышы һәм юлбасарлар турында сөйләп бирде. Аннан кулын туганына сузды да болай диде:

— Әй, туганым минем,—диде ул,—без синең белән икебез дә бер ата, бер ана балалары. Тау куышындагы байлыкны әйдә синең белән урталай бүлик. Мин тау куышына ничек керергә һәм юлбасарлардан ничек сакланырга икәнен беләм. Акчаларның һәм энҗе-мәрҗәннәрнең яртысын сиңа бирим, — ул синең бөтен гомереңә җитәр.

— Яртысын гына түгел, бөтенесен үземә алырга телим!—дип кычкырды Касыйм һәм Гали-Бабаның кулын этеп җибәрде.—Әйт тизрәк, тау куышына ничек керергә? Әгәр әйтмәсәң, патшага җиткерәм. Ул синең башыңны чабып өзәргә кушачак.

— Нигә син мине патша белән куркытасың?—диде Гали-Баба.—Теләсәң тау куышына ялгыз бар. Ләкин син андагы алтын һәм энже-мәрҗәннең барысын да барыбер төяп кайта алмассың. Әгәр дә син бер ел буена көн-төн бертуктаусыз ташып торсаң да андагы алтын-көмешнең бары яртысын гына алып кайтып бетерә алырсың!

Гали-Баба Касыймга тау куышын ничек эзләп табарга икәнен өйрәтте һәм: „Симсим, ач ишекне!“ дигән сүзләрне онытмаска кушты.

— Онытмам,—диде Касыйм,—Симсим... ул киндер төслерәк бер үсемлек бугай. Хәтерләрмен.

Икенче көнне иртә белән Касыйм ун качыр иярләде дә, һәр качырга ике зур-зур сандык асып урманга китте. Ул үзенең качырларын урман кырыена печәнгә җибәрде дә, кыядагы ишекне эзләп тапты, аннан ишек каршысына басты да бөтен көченә кычкырып салды:

— Әй, Симсим, ач ишекне!

Ишек ачылып китте. Касыйм эчкә керде, ул кергә ишек яңадан бикләнде.

Касыйм кыйммәтле нәрсәләр белән тулы тау куышын күргәч, шатлыгыннан нишләргә белмәде. Ул баскан урынында биеп торды, аннан түргә таба йөгереп, ни әләкте шуны күтәреп алды: кочак-кочак кыйммәтле кызыл маллар, кисәк-кисәк алтыннар, кувшин һәм тәлинкәләр—барысын да кочагына җыйды. Аларны ташлады да стеналардагы алтын кылыч һәм калканнарга үрелде, алтын акчаларны куш учлап алды да куенына тутырды. Ул бер сәгать буена шулай йөрде, ләкин андагы байлыкны барыбер алып бетерә алмады. Ниһаять, ул шундый уйга килде:

„Минем вакытым күп. Хәзергә качырларым күтәрә алырлык кадәресен алып торыйм да, аннан соң тагын килермен. Мин моннан соң бирегә алтыннарны ташып бетергәнче көн дә килермен“.



Ул бер капчык алтын алды да ишеккә таба өстерәде. Ишек бикле иде. Касыйм ишекне ача торган тылсымлы сүзләрне әйтмәкче булды, ләкин ул аларны онытып җибәргән иде. Бары тик ниндидер үсемлек исемен әйтергә кирәклек кенә аның исендә калган иде. Һәм ул:

— Борчак, ач ишекне! — дип кычкырды.

Ләкин ишек ачылмады. Касыйм бераз куркып китте. Уйлап-уйлап торды да тагы кычкырып җибәрде:

— Бодай, ач ишекне!

Ишек селкенеп тә карамады, Касыйм куркуыннан инде бернәрсәне дә исенә төшерә алмады, һәм үзе белгән барлык үсемлекләрнең исемен кычкырырга тотынды.

— Солы, ач ишекне!

— Киндер, ач ишекне!

— Ясмык, ач ишекне!

Ләкин ишек ачылмады. Касыйм бу тау тишегеннән беркайчан да чыга алмаячагын аңлады. Ул алтынлы капчыкка утырды да елап җибәрде.

Касыйм тау тишегендә маташкан арада юлбасарлар бай сәүдәгәрләрнең алтыннарын, кыйммәтле малларын талап йөриләр. Алар бу әйберләрнең барысын да шушы тау куышына алып кайталар. Кайтышлый, урманга җитәрәк атаман бер читтә тыныч кына печән ашап йөрүче качырларны күрә.

— Болар нинди качырлар икән? — диде атаман. — Иярләренә сандыклар бәйләнгән. Мөгаен, кем дә булса безнең тау тишеге турында белгән һәм безне таларга килгән!

Ул юлбасарларга шауламаска кушты һәм ишек төбенә килеп әкрен генә эндәште:

— Симсим, ач ишекне!

Ишек ачылып китте. Юлбасарлар акча капчыгы артына качып калырга маташкан Касыймны күреп алдылар. Атаман алга ташланды һәм, кылычы белән кизәнеп, Касыймның башын чабып өзде.

Юлбасарлар Касыймның гәүдәсен тау куышында калдырдылар. Тау куышыннан чыгып атларына атландылар да Касыймның качырларын куып алып киттеләр.

Ә Фатыймага килсәк, ул бөтен көн буе тәрәзә төбендә утырды. Алтын тутырылган сандыклы качырларның урманнан кайтуларын көтте ул. Ләкин вакыт үтте дә үтте, ә Касыйм һаман да күренмәде. Фатыйма көн буе, төн буе утырды тәрәзә төбендә, ә иртән Гали-Баба янына йөгереп керде.

Гали-Баба болай диде:

— Борчылма, Фатыйма. Мин хәзер урманга барам да Касыймга нәрсә булганын белеп кайтам.

Гали-Баба шунда ук ишәгенә атланып урманга, әлеге тау куышына китте. Тау куышына керүгә үле туганының акча капчыклары өстендә ятканын күрде.

Гали-Баба Касыймның гәүдәсен тау куышыннан алып чыкты, зур капчыкка тыкты һәм, ишәгенә салып кайгыра-кайгыра өенә кайтып китте. Кайтканда үз-үзенә сөйләнеп кайтты:

„Комсызлык Касыймны менә нәрсәгә китереп җиткерде! Әгәр дә акчаларны минем белән бүлешергә риза булган булса, комсызланып барысын да үзенә тартып алырга теләмәгән булса, ул исән калган булган булыр иде“.

Гали-Баба Касыймны бик зурлап күмде, ләкин туганының ничек үлгәнен беркемгә дә әйтмәде. Ә Фатыйма, Касыймның җеназасын зиратка илтүчеләргә: „Иремне урманда кыргый ерткычлар талап үтергәннәр“,— дип сөйләде.

Касыймны җирләгәч, Гали-Баба Фатыймага болай диде:

— Beләсеңме нәрсә, Фатыйма, син йортыңны безгә сат, үзең дә шунда безнең белән бергә торырсың. Ул чакта безгә яңа йорт салып торуның кирәге дә калмас, безнең белән булгач, сиңа да артык куркыныч булмас. Ярыймы?

— Әй, Гали-Баба, — диде Фатыйма, — минем йортым — синең

йортың. Минем барлык нәрсәләрем—синеке. Үзегез белән торырга рөхсәт итсәң, миңа бернәрсә дә кирәк түгел.

— Алайса бик яхшы, — диде Гали-Баба, һәм алар — Зәйнәп, Фатыйма, Гали-Баба — өчәү бергә тора башладылар.

Гали-Баба тау куышына тагы берничә тапкыр барып, аннан бик күп алтын, кыйммәтле киемнәр, паласлар, савыт-сабалар алып кайтты. Хәзер аның кухнясында һәр көнне үз гаиләсе өчен генә түгел, ә бәлки ашарларына булмаган фәкыйрь күршеләре өчен дә аш хәзерләнде. Бу ашлар өчен рәхмәт укучыларга Гали-Баба болай ди торган иде:

— Иртәгә дә килегез, үзегез белән барлык фәкыйрьләрне алып килегез. Рәхмәт әйтер урын юк. Мин бит сезне урманда бүреләр тарафыннан үтерелгән туганым акчасына сыйлыйм. Ул бит бай кеше иде...

Тиздән барлык ярлылар һәм хәерчеләр Гали-Баба өенә көндез дә һәм кич тә аш ашарга йөри башладылар, һәм шәһәр кешеләре Гали-Бабаны бик яраттылар.

Гали-Баба, Зәйнәп һәм Фатыйма турында хәзергә шул гына. Юлбасарларга килсәк, алар берничә көннән соң тагы тау куышына килделәр һәм дошманнарының гәүдәсе югалганлыгын, ә акча капчыкларының җирдә таркалып ятканын күрделәр.

— Безнең куышка тагы кемдер кергән! — дип кычкырды атаман.—Күптән түгел генә мин дошманымны үтергән идем, ә алар берничәү икән! Безнең әйбергә кулын сузган һәрбер кешене үтермәсәм, исемем Сыңаркүз Хәсән булмасын! Батыр юлбасарлар! Сезнең арагызда шәһәргә барып, безне талаган кешене эзләп табудан курыкмаслык кыю кеше табылырмы? Бу эшкә куркак яки йомшак кеше тотынмасын! Бу эшне бары хәйләкәр һәм җитез кеше генә башкарып чыга алачак!

— Әй, атаман! — диде юлбасарларның берсе,— шәһәргә барып дошманыбызны эзләп табу миннән башка һичбер кемнең кулын-

нан килмәс. Мине юкка гына Башкисәр Әхмәт дип йөрмиләр бит. Ә инде мин аны эзләп таба алмасам, мине теләсәң ни эшләтерсең.

— Яхшы, Әхмәт,— диде атаман.— Мин сиңа бер көн вакыт бирәм. Әгәр дә син безнең дошманыбызны эзләп таба алсаң, мин сине үземнең ярдәмчем итәрмен. Ә инде таба алмасаң, кайтып та йөрмә. Мин синең башыңны чабып өзәчәкмен!

— Тыныч бул, атаман, бер көн дә үтмәс, син үзеңнең дошманыңның кайда икәнен белерсең,— диде Әхмәт.— Бүген мине кичкә таба шушында, урманда көтегез.

Ул үзенең өстендәге юлбасар киемен салып ташлады. Зәңгәр ефәк җилән, кызыл сафиян итекләр киде, башына чалма чалды да шәһәргә китеп барды.

Ул шәһәргә килеп кергәндә бик иртә иде әле. Базар җыйналмаган һәм барлык кибетләр дә бикле иде. Бары бер башмакчы карт кына үзенең кормасы астында коралларын таратып салган да, эш бирүчеләр килгәнне көтеп утыра иде.

Башкисәр Әхмәт аның янына килеп сәлам бирде һәм болай диде:

— Хәерле иртә, бабай. Син эшкә бигрәк иртә чыккансың! Әгәр дә сине күрмәсәм, базар башланганчы миңа бик озак көтеп торырга туры килгән булыр иде.

Башмакчы дигәнебез—Мостафа исемле бер карт иде. Ул Башкисәр Әхмәттән:

— Ә сиңа нәрсә кирәк соң?—дип сорады.

— Мин сезнең шәһәрдә ят кеше,—дип җавап бирде Әхмәт.— Мин бирегә бары бүген төнлә белән генә килдем, һәм таң атып шәһәр капкалары ачылганчы көтеп тордым. Бу шәһәрдә минем туганым, бер бай сәүдәгәр яшәгән иде. Мин аны күрергә дип ерак илләрдән килдем, һәм шәһәргә җитәрәк, аны урманнан үле килеш тапканнар дип ишеттем. Хәзер инде аның туганнарын ничек итеп эзләп табарга белмим. Мин дә аларның кайгыларын уртаклашыр идем.

— Син үзеңнең туганыңны бай сәүдәгәр иде дисең? — дип сорады башмакчы.— Күптән түгел генә безнең шәһәрдә бер бай сәүдәгәрне күмделәр, җеназасында мин дә булдым. Сәүдәгәрнең хатыны аны урманда бүреләр талаган дип сөйләде, ләкин мин бер кешедән моның дөрес түгеллеген ишеттем. Аның әйтүенә караганда, бу сәүдәгәрне урманнан башы өзелгән хәлдә тапканнар һәм капчыкка салып, яшерен рәвештә, өенә алып кайтканнар.

Башкисәр Әхмәт бу сүзләрне ишеткәч, бик шатланды. Башмакчы сөйләгән бай сәүдәгәрнең тау куышында атаман тарафыннан үтерелгән кеше икәнен аңлады.

— Син миңа аның йортын күрсәтә аласыңмы? — дип сорады Башкисәр Әхмәт башмакчыдан.

— Күрсәтә алам, — дип җавап бирде башмакчы.— Ләкин алай минем эшем тукталып торыр бит. Кинәт берәр кеше килер дә туфли тектерергә миңа заказ бирергә теләр, ә мин урынымда булмам.

— Менә сиңа бер динар, — диде Әхмәт, — ә минем туганымның йортын күрсәткәч, мин сиңа тагы бер динар бирермен.

Мостафа шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

— Юмартлыгың өчен рәхмәт сиңа! Бу хәтле акча эшләү өчен миңа ай буена туфлилар ямап утырырга туры килер иде. Әйдә киттек! — диде.

Һәм башмакчы, Башкисәр Әхмәтне Касыйм йорты янына алып килде.

— Үтерелгән сәүдәгәр йорты шушы, хәзер бирегә аның туганы күчте, — диде Мостафа.

„Миңа шул кеше кирәк тә“ дип уйлап куйды Әхмәт. Ул Мостафага тагы бер динар бирде. Мостафа башын ия-ия рәхмәтләр әйтеп базарына китеп барды.

Бу шәһәрдәге йортларның барысы да биек коймалар белән әйләндереп алынганнар иде, урам якка бары капкалары гына чыгып тора иде. Шуңа күрә бу шәһәрдәге таныш булмаган йортны хәтерләү ансат түгел иде.

— Башка вакытта ялгышмас өчен дошман йортын билгеләп китәргә кирәк,— диде Әхмәт үз-үзенә.

Ул кесәсеннән бер кисәк акбур алды да капкага аркылы-торкылы сызык сызды, ә аннан соң кайтып китте, кайтканда шатлана-шатлана үзенә-үзе болай дип сөйләнде:

— Хәзер инде мин бу йортны онытмам һәм иртәгә мин анда иптәшләремне алып килермен. Шулай итеп атаманның ярдәмчесе булып китәрмен!

Әхмәт китеп өлгерүгә өйдән Гали-Бабаның асравы килеп чыкты. Бу асрау Мәрҗәнә исемле кыю һәм акыллы кыз иде. Аның ит һәм икмәк алырга барышы иде, капканы япканда ул борылып карады һәм капкага акбур белән сызылган аркылы-торкылы сызыкны күрде.

„Кем безнең капканы болай пычратып китте икән?— диде Мәрҗәнә.—Мөгаен урам малайларыдыр әле. Юк. Тәре бик югары сызылган. Аны зур кеше сызган булырга тиеш. Һәм аны сызучы безгә каршы берәр начарлык уйлаган булса кирәк. Мөгаен соңыннан килеп безне талап яки үтереп китәр өчен безнең өйне билгеләп киткәндер. Тукта әле, мин аны эзеннән яздырыйм“.

Мәрҗәнә өйгә кереп бер кисәк акбур алып чыкты да күрше өйләрнең барысына да тәре куеп барды. Ә аннан үз юлына китте.

Ә юлбасар тау куышына йөгереп кайтып җиткәч, шатлыгыннан нишләргә белмичә кычкырып җибәрде:

— Тыңла, атаман! Барыгыз да тыңлагыз! Мин дошманның йортын эзләп таптым! Һәм тәре белән билгеләп кайттым. Мин иртәгә аны сезгә күрсәтермен!

— Яшә, Башкисәр Әхмәт!—диде атаман.—Иртәгә иртә белән һәрберегез хәзер булып торыгыз! Җилән асларыбызга үткен пычаклар яшереп, дошман өенә китәрбез.

— Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз, атаман —диештеләр юлбасарлар, һәм барысы да Әхмәтне эше уңышлы барып чыгу белән тәбрик итә башладылар.

Ә Башкисәр Әхмәт тәкәбберләнеп йөрде һәм болай дип шапырынды:

— Менә күрерсез, мин атаманның ярдәмчесе булам.

Ул, таң атканны көтеп, бөтен төн буе йокламады. Таң атуга, сикереп торып юлбасарларны уятты. Юлбасарлар киң бохар җиләннәре, ак чалмалар, кәкре очлы туфлилар киделәр. Үткен хәнҗәрләрен җилән эчләренә яшерделәр дә шәһәргә китеп бардылар.

Шәһәрдә күргәнбер кеше юлбасарларны:

— Болар Бохара кешеләре, алар безнең шәһәрне күрергә килгәннәрдер,— диештеләр.

Иң алдан Әхмәт белән атаман барды. Әхмәт үзенең иптәшләрен шәһәр буенча озак өстерәп йөрде, йөри торгач, кирәк урамны эзләп тапты.

— Карагыз! — ди ул,— менә шушы йорт. Әнә күрегез, капкасында тәре бар!

— Менә бусы да тәреле капка ич,— диде икенче бер юлбасар.— Безнең дошман боларның кайсысында тора соң?

— Әнә теге капкада да тәре! Менә бусында да! Һәм менә монда да тәре! Монда йорт саен тәре!—дип кычкырдылар юлбасарлар.

Атаманның ачуы чыкты:

— Бу нинди эш! Хәйләдә кемдер сине уздырып җибәргән, Әхмәт! Син кушканны үти алмадың, шулай булгач, сиңа моннан ары безнең белән юлбасарлык итеп йөрергә туры килмәс. Мин үзем синең башыңны чабып өзәчәкмен! — диде.

Һәм урманга кайтуга каты күңелле атаман Әхмәтнең башын чабып өзде, ә аннан соң болай диде:

— Дошманның йортын эзләп табуны тагы кайсыгыз үз өстенә ала? Кемнең кыюлыгы җитә? Бу эшкә йомшак яки ялкау кеше тотынып та карамасын!

— Әй, атаман, миңа сынап карарга рөхсәт ит,— диде Пеләш Мөхәммәт исемле бер юлбасар.—Мин карт кеше, һәм мине ансат

кына алдый алмаслар. Ә инде кушканыңны үти алмасам, мине дә Әхмәтне үтергән төсле җәзалап үтерерсең!

Атаман:

— Бар, Мөхәммәт! Сине иртәгә кичкә кадәр көтәрмен. Ләкин кара аны, әгәр дә син дошманның йортын табып миңа күрсәтә алмасаң, кызганып тормам,— диде.

Икенче көнне иртән Пеләш Мөхәммәт шәһәргә китте. Әхмәт юлбасарларга башмакчы Мостафа турында сөйләгән булган икән, Мөхәммәт тә туп-туры шуның янына килде. Ул да башмакчы белән Әхмәт сөйләгән сүзләрне үк сөйләште. Һәм үтерелгән сәүдәгәрнең йортын күрсәтсә, Мостафага ике динар акча бирергә вәгъдә итте. Мостафа шатлыгыннан Мөхәммәтне Гали-Бабаның капка төбенә кадәр илтеп куйды.

— Миңа да йортны, ничек булса да, билгеләп куярга туры килер,—дип уйлады Мөхәммәт. Ул, юлда аунап яткан бер кисәк кирпечне алды да, капканың югары почмагына кечкенә генә тәре ясап куйды.

„Бу тәрене миннән башка беркем күрмәс,—дип уйлады ул.— Тизрәк, йөгереп кайтыйм да атаманны алып килим“. Һәм ул тиз-тиз үзенең иптәшләре янына кайтып китте. Бу вакытта Мәрҗәнә базардан кайтып килә иде, ул үзләренең капкалары яныннан кемнеңдер посып кына үтеп, юл буенча йөгереп киткәнен күргәч, шиккә төште.

Мәрҗәнә капка янына килеп җентекләп карады һәм капканың югары почмагында кечкенә генә кызыл тәре күрде.

„Безнең капкага билге ясап йөрүче менә кем икән,—дип уйлады Мәрҗәнә,—тукта әле мин сине акылга утыртыйм,—диде дә җирдән бер кисәк кирпеч алып үз урамнарындагы капкаларның барысына да тәре ясап чыкты.

— Я, менә хәзер безнең йортны эзләп кара, кичәге шикелле үк бүген дә һичнәрсә чыгара алмассың,—дип кычкырды.

Ә Пеләш Мөхәммәт бөтен юл буена бертуктаусыз йөгерде. Ниһаять, сулуы кабып тау куышына кайтып керде.



— Әйдәгез тизрәк! — дип кычкырды ул. — Мин билгене шундый итеп ясадым, хәзер инде дошман кайда да китә алмас. Җыеныгыз, тизрәк булыгыз!

Юлбасарлар җиләннәрен киделәр дә Мөхәммәт артыннан киттеләр. Алар шәһәргә яктыда килеп җитү өчен бик тә ашыгып бардылар. Шулай да бары кояш баер алдыннан гына килеп җиттеләр. Пеләш Мөхәммәт, таныш урамны эзләп тапты да, атаманны иң зур матур капка алдына алып килде һәм капканың югары почмагындагы кызыл тәрегә бармагы белән төртеп күрсәтте.— Күрәсеңме? Бу мин ясаган билге,— диде ул.

Күрше йортның капкасы төбенә туктаган икенче бер юлбасар:

— Ә бусы кем ясаган билге? Монда да тәре бар ич,— дип кычкырды.

— Нинди тәре? — дип акырды Мөхәммәт.

— Кызыл,— дип җавап бирде теге юлбасар,— әнә теге капкада да нәкъ шундый ук тәре, каршы яктагы йортта да. Син атаманга үз тәреңне күрсәткән арада мин бөтен капкаларны карап килдем.

— Әй, Мөхәммәт, Мөхәммәт, хәйләдә синнән дә уздырып җибәргәннәрмени? Син үзең яхшы юлбасар булсаң да кушканны үти алмагансың. Сине дә кызгану булмаячак! — диде атаман.

Һәм Мөхәммәт тә Әхмәт шикелле һәлак булды. Шулай итеп атаманның шайкасында кырык түгел, ә утыз сигез генә юлбасар калды.

„Бу авыр эшкә минем үземә тотынырга кирәк булыр ахрысы. Минем кешеләрем яхшы сугышалар, урлый һәм талый беләләр, ләкин алар хәйләне һәм алдауны булдыра алмыйлар“, — диде атаман.

Икенче көнне иртә белән Сыңаркүз Хәсән, юлбасарлар атаманы, шәһәргә үзе килде. Ул килгәндә базарда сәүдәнең иң кызган чагы иде, атаман башмакчы Мостафаны эзләп тапты да янына килеп чүгәләп болай диде:

— Әй, бабай, нигә син шул хәтле күңелсез? Әллә эшең юкмы?

— Эш күптәннән бирле юк инде ул, әгәр дә язмыш миңа ярдәм кулын сузмаган булса, мин инде мөгаен ачлыктан үлгән булыр идем. Өченче көн бик иртән минем яныма бер юмарт кеше килде дә үзенең агасының туганнарын эзләп йөрүен сөйләде. Ә мин аның агасының өе кайда икәнне белә идем, юл күрсәттем, шуның өчен бу чит ил кешесе миңа төгәл ике динар бүләк итте. Кичә минем яныма икенче бер чит ил кешесе килде, бусы да миннән үзенең күптән түгел генә үлгән агасын сорашты. Мин аны да шул ук йорт янына алып бардым, бусыннан да ике динар тамды. Ә бүген инде менә төш вакыты житте, ләкин минем яныма берәү дә килмәде, мәетнең башка туганнары юктыр күрәсең.

Мостафаның сүзләрен ишетүгә, атаман кычкырып елап җибәрде һәм болай диде:

— Сине очрату минем өчен нинди зур бәхет! Урманда үтерелгән кешенең мин өченче туганы булам. Мин Ерак Көнбатыштан килдем һәм минем кадерле туганымны үтерүләре турында бары кичә генә ишеттем. Без дүрт туган идек һәм дүртебез дүрт якта яши идек. Менә хәзер инде без сезнең шәһәргә килеп җыйналдык, ләкин агабыз, мескен, үлгән икән. Син мине аның йортына алып бара күр, мин дә сиңа агай-энеләрем түләгән кадәр үк түләрмен.

— Яхшы,— диде карт шатланып.— Ә аның тагы башка туганнары юкмы?

— Юк,— диде атаман, авыр сулап.— Без дүртәү идек, ә хәзер инде өчкә генә калдык.

Мостафа карт шулай ук авыр сулап болай диде:

— Сезнең шулай аз булуыгыз кызганыч. Әйдә киттек.

Ул атаманны Касыйм йорты янына алып килде, аяк ялын алды да кайтып китте, ә атаман чаттан алып Касыйм йортына кадәр булган капкаларны санап чыкты. Шулай булгач, капкага билге ясап торуның да кирәге калмады. Аннан иптәшләре янына кайтты.

— Әй, юлбасарлар, мин бер хәйлә уйлап чыгардым, әгәр дә бу хәйлә барып чыга калса, без дошманны тотып үтерербез һәм



тау куышыннан ул ташыган байлыкның барысын да кире тартып алырбыз. Мине тыңлагыз һәм минем боерыкларымның барысын да үтәп барыгыз!— диде атаман.

Һәм ул бер юлбасарына шәһәргә барып таза-таза егерме качыр һәм кырык май чүлмәге алып кайтырга кушты.

Ә зур-зур чүлмәкләр төялгән качырларны алып кайткач, атаман юлбасарларга шул чүлмәкләргә кереп утырырга боерды.

Юлбасарлар кереп утыргач, атаман чүлмәкләрнең авызларын пальма яфраклары белән томалап чыкты, һәм чирәм белән бәйләде. Кешеләр тончыгып үлмәсеннәр өчен, яфракларны тишкәләде. Буш калган ике чүлмәккә зәйтүн мае тутырды, һәрбер чүлмәкнең тышын (боларында да май дип белсеннәр өчен) шул ук май белән майлап чыкты.

Атаман үзе бай сәүдәгәрләр кия торган кием киде дә качырларын куа-куа шәһәргә юнәлде.

Кич булды, караңгы төшә башлады. Атаман туп-туры Касыйм өенә таба китте һәм капка төбендә, шат һәм ачык чырайлы бер кеше утырып торганны күрде. Бу — Гали-Баба иде. Атаман аның янына килде дә кулын җиргә тидергәнче башын түбән иде.

— Хәерле кич, хөрмәтле сәүдәгәр,— диде ул.— Мин үзем ерак ил кешесе. Кыйммәтле май алып килгән идем, һәм бу майларны сезнең шәһәрдә сатарга уйлаган идем. Ләкин минем качырларым ерак юл йөрү сәбәпле ардылар, шуңар күрә әкрен килделәр. Мин шәһәргә кергәндә кич булган һәм барлык кибетләр бикләнеп өлгергәннәр иде. Мин үземә кунып чыгарлык урын эзләп бөтен шәһәрне йөреп чыктым, ләкин чит ил кешесен берәү дә кертәсе килмәде. Һәм менә синең яныңнан узып барышлый ачык чырайлы кеше икәнеңне күрдем. Йортыңда бер генә төн кунып чыгарга рөхсәт итмәссеңме икән? Мин үземнең майларымны ишек алдына куеп торырмын, ә иртәгә иртүк базарга алып барып сатармын. Ә аннан үз илемә кайтып китәрмен дә барысына да синең яхшылыгың турында сөйләрмен.

— Кер, кер, мосафир,— диде Гали-Баба.— Миндә урын күп. Качырларыңны тугар да, ашарларына сал. Ә аннан бик әйбәтләп аш ашарбыз. Кара әле, Мәрҗәнә, этләрне чылбырла, кунакны тешләмәсеннәр!

— Әй, хөрмәтле сәүдәгәр, рәхмәт сиңа!— диде юлбасарлар атаманы.— Минем соравымны үтәгәнең өчен синең барлык теләкләрең кабул булсын!

Ул, үзенең качырларын ишек алдына кертте дә, юлбасарларны имгәтмәс өчен, чүлмәкләрен әкрен генә стена буена тезеп куйды. Ә аннан чүлмәкләргә таба иелеп:

— Әкрен генә утырыгыз һәм кузгалмагыз, төнлә белән мин үзем чыгып сезне өйгә алып керермен,— дип пышылдады.

Чүлмәкләрдәге юлбасарлар да:

— Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз, атаман!— дип пышылдап җавап бирделәр.

Атаман өйгә керде дә кичке аш хәзерләнгән бүлмәгә күтәрелде. Гали-Баба палас япкан тәбәнәк скамьяда аны көтеп утыра иде. Кунакны күрүгә, ул Мәрҗәнәгә кычкырды:

— Әй, Мәрҗәнә, тавык кыздырырга һәм күбрәк итеп баллы коймак хәзерләргә куш! Мин кунагымның безнең сыебыздан канәгать булуын телим!

— Тыңлыйм һәм буйсынам, боларның барысын да мин үзем, үз кулларым белән хәзерләп китерермен,— диде Мәрҗәнә.

Ул кухняга йөгереп чыкты. Тиз генә камыр изеп ташлады, пешерә башларга дип кенә торганда өйдә май юк икәнен белде.

— Менә бәла!— дип кычкырды Мәрҗәнә.

Кинәт ул, маңгаена шапылдатып сукты да, шатланып болай диде:

— Аңгыра да инде мин! Май юк дип пошынам, ә анда, ишек алдында кырык чүлмәк май бар. Кунакның әз генә маен алып торыйм да, иртәгә таң атар-атмас базардан сатып алып чүлмәгенә салып куярмын.

Ул шәм яндырды да ишек алдына чыкты. Төн караңгы һәм

салынкы иде. Тирә-як тын, бары кое янындагы качырлар гына пошкырышалар һәм йөгәннәрен зеңелдәтеп торалар иде.

Мәрҗәнә шәмен югары тоткан хәлдә чүлмәкләр янына килде.

Һәм иң якындагы чүлмәк—нәҗъ майлы чүлмәк булып чыкты. Мәрҗәнә чүлмәкнең авызын ачты да үз чүлмәгенә май агызырга тотынды.

Бу вакытта юлбасарлар чүлмәкләр эчендә бөрешеп утырудан бөтенләй туеп беткәннәр иде. Аларның сөякләре шул хәтле авыртты, бөтенләй түзәрлек хәлләре калмаган иде. Юлбасарлар Мәрҗәнәнең аяк тавышын ишеткәч, атаманнары килә дип уйладылар, һәм аларның берсе:

— Килдеңме, атаман? Тизрәк бу ләгънәт чүлмәкләрдән чыгарга рөхсәт ит һәм бу йортның хуҗасы—дошманыбыз белән алышбирешне өзәргә куш!—диде.

Мәрҗәнә чүлмәк эченнән тавыш килгәнне ишеткәч, куркуыннан чак-чак кына егылып китмәде, кулындагы шәмен чак-чак кына төшереп җибәрмәде. Ләкин ул акыллы һәм батыр кыз иде; май сатучының усал һәм юлбасар икәнен, ә чүлмәкләрдә аның кешеләре икәнен, Гали-Бабага куркыныч үлем бармак янаганны шунда ук аңлап алды.

Ул тавыш ишетелгән чүлмәк янына килде дә ирләр тавышы белән болай диде:

— Тиздән вакыт җитәр! Кычкырма, югыйсә этләр ишетеп алырлар. Аларны хәзер чылбырларыннан ычкындырдылар.

Аннан ул икенче бер чүлмәк янына килде дә:

— Монда кем?—дип сорады.

Чүлмәк эченнән:

— Мин, Хәсән,—дигән тавыш ишетелде.

— Әзер тор, Хәсән, тиздән мин сине чыгарам.

Шулай итеп ул бөтен чүлмәкләрне дә йөреп чыкты һәм утыз сигез чүлмәктә юлбасар, бары икесендә генә май икәнен белде.

Мәрҗәнә, май тутырган чүлмәген күтәрде дә, кухняга йөгереп керде. Майны кайнаганчы утта кыздырды. Аннан соң юлбасар

утыра торган бер чүлмәккә китереп салды, юлбасар кычкыра да алмый калды, шунда ук үлде. Бер дошман белән эшне бетергәч, ул тагын май кайнатты да икенче бер юлбасар өстенә сипте, шулай итеп бөтенесен үтереп бетерде. Ә аннан соң табада бик күп итеп коймак пешерде дә матурлап көмеш савытка тезеп салды, өстенә май сипте һәм Гали-Баба белән кунагы утыра торган бүлмәгә кертте. Гали-Баба юлбасарлар атаманын кыстый-кыстый сыйлады, теге шул хәтле ашады, селкенә дә алмый башлады. Ул кулларын корсагына куеп берничә мендәр өстенә ятты да авыр суларга тотынды.

Гали-Баба, кунагы ашап туйгач, аның күңелен ачарга теләде. Һәм Мәрҗәнәгә кычкырды:

— Әй, Мәрҗәнә, кунак хөрмәтенә иң яхшы бер биюеңне биеп җибәр әле.

Мәрҗәнә башын түбән иеп җавап бирде:

— Тыңлыйм һәм буйсынам, әфәндем, бөркәнчегемне генә алып килергә рөхсәт ит, мин бөркәнчек ябынып биергә телим.

— Бар, алып кил,— диде Гали-Баба.

Мәрҗәнә үз бүлмәсенә йөгерде, чигеп эшләнгән бөркәнчегенә төренде; бөркәнчек астына үткен хәнҗәрен яшерде. Аннан соң килде дә бии башлады.

Гали-Баба белән юлбасарлар атаманы Мәрҗәнәнең биюен карап утырдылар һәм кәефләнеп башларын чайкадылар. Мәрҗәнә биегән саен атаманга якынайды. Һәм атаман өстенә мәче шикелле сикереп кунды да хәнҗәрен йөрәгенә кадады. Юлбасар, бик каты акырып йөзтүбән капланды да, үлде. Гали-Баба куркуыннан катып калды. Ул, Мәрҗәнә акылдан язган икән дип уйлады.

— Кайгы миңа! Ни эшләдең син, акылсыз нәрсә? Минем өемдә мосафир үтерелде! Оят һәм хурлык бу минем өчен!— дип кычкырды ул.

Мәрҗәнә, Гали-Баба алдына тезләнде дә, болай диде:

— Иң элек син мине тыңла, аннан теләсәң ни эшләтерсең. Әгәр мин гаепле икән, мин аны үтергән шикелле, син дә мине



үтер.— Һәм ул Гали-Бабага чүлмәкләрдә юлбасарлар икәнлекне ничек итеп белүен һәм аларны ничек итеп үтереп бетерүен сөйләп бирде.

Гали-Баба боларның тау куышындагы юлбасарлар икәнен, Касыймны үтерүчеләр икәнен шунда ук аңлап алды.

Ул, Мәрҗәнәне кулларыннан тотып торгызды да, каты итеп кычкырып җибәрде:

— Тор, Зәйнәп, Фатыйманы уят! Безгә куркыныч үлем бармак янаган, ә бу кыю һәм акыллы кыз безнең барыбызны да коткарып калган.

Зәйнәп белән Фатыйма шунда ук йөгереп килеп Мәрҗәнәне кочып алдылар. Ә Гали-Баба:

— Син моннан болай йорт хезмәтчесе түгел, Мәрҗәнә, бүгеннән башлап син безнең белән бертуган сеңелебез шикелле торырсың,— диде.

Һәм алар, шул вакыттан башлап, үлгәнче шулай тыныч һәм рәхәт яшәделәр.



ГАЛИ-БАБА

И


СОРОК РАЗБОЙНИКОВ

(на татарском языке)

Техник редакторы *М. Шарафутдинова*
Корректоры *Р. Галиаскарова*

Наборга бирелде 19/XI 1949 ел. Басарга кул куелды 4/I 1950 ел. ПФ 01309
Кәгазь форматы 70×92$^{1}/_{16}$ Учет-изд. 1,76 таб. Басма табак 2,5
Табакта 41700 хәреф. Заказ 0357 Тираж 10.000

ТАССР Министрлар Советы янындагы Издательстволар һәм полиграфия идарәсенең Татполиграф типографиясе. Казань, Мыславский ур., йорт 9,



1 сум 50 тиен